ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 403-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, Р.Н. Мөхәммәдиев, А.Г. Фомичёв, В.Г. Чагин, Т.Н. Шаһиваәлиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 403-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1911-VI ДС

403-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
С.М. Захарова,
Р.Н. Мөхәммәдиев,
А.Г. Фомичёв,
В.Г. Чагин,
Т.Н. Шаһивәлиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) Татарстан Республикасының дәүләт милке булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибен, мондый карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибен билгеләү;»;

2) 4 статьяда «һәм тәмәке әйберләре» сүзләрен «, тәмәке әйберләре яисә никотинлы продукция» сүзләренә алмаштырырга, «традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне пропагандалый торган» сүзләрен «традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне һәм (яисә) өстенлекләрне пропагандалый йә күрсәтә торган мәгълүматтан, педофилияне пропагандалый торган мәгълүматтан, балаларда җенесне алмаштыру теләге уятырга сәләтле мәгълүматтан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмасын яисә муниципаль оешманы үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү балаларның тормыш эшчәнлеген, аларга белем бирүне, аларны үстерүне, аларның ялын һәм аларны савыктыруны, аларга медицина ярдәме күрсәтүне, балалардагы авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклауны һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең уңай бәяләмәсе нигезендә рөхсәт ителә.

Дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектының билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү Федераль законның 13 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацы нигезендә билгеләнгән очракларда рөхсәт ителә.

Балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү граждан законнарында билгеләнгән очракларда дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган һәм мондый оешмаларның, шул исәптән яңа төзелә торган, мөлкәти комплексларына керә торган балалар өчен социаль инфраструктура объектларының билгеләнешен үзгәртмичә, Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмасын яисә муниципаль оешманы бетерү турында карар кабул итү мондый оешманың мөлкәти комплексында дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектлары булмаган очракта йә мондый оешманың мөлкәти комплексына керә торган балалар өчен социаль инфраструктура объектларының әлеге өлешнең икенче абзацы нигезендә билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү очрагында рөхсәт ителә.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән карарны кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрүнең гомуми принциплары, бу бәяләүнең критерийларын да кертеп, шулай ук мондый карарны кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен булдыруның һәм аның эшчәнлегенең гомуми принциплары Федераль законның 13 статьясындагы 2 пунктының бишенче абзацы нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасының дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын яисә муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибе, мондый карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибе, әлеге өлешнең бишенче абзацы нигезендә билгеләнгән гомуми

принципларны исәпкә алып, тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.»;

б) 3 өлештә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының дәүләт милке» сүзләреннән соң «яисә муниципаль милек» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру өчен билгеләнгән объектларны урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнешен һәм (яисә) рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү, Федераль законның 13 статьясындагы 2 пункты нигезендә дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектының билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү рөхсәт ителә торган очраклардан һәм мондый җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алу очракларыннан тыш, тыела.»;

икенче абзацта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Муниципаль милек булып торган һәм балаларга белем бирү, аларны үстерү, аларның ялы һәм аларны савыктыру, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм алардагы авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән мөлкәт муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә кулланыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законын «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 5 декабрендәге 478-ФЗ номерлы Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 635-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында эшләнде.

Баланы аның сәламәтлегенә, әхлакый һәм рухи үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан, пропагандадан һәм агитациядән яклау турында Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына баланы традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне һәм (яисә) өстенлекләрне пропагандалый йә күрсәтә торган мәгълүматтан, педофилияне пропагандалый торган мәгълүматтан һәм балаларда җенесне алмаштыру теләге уятырга сәләтле мәгълүматтан яклау турында нигезләмә өстәү тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр балалар өчен социаль инфраструктура объектларының билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү тәртибен, Россия Федерациясе субъектының дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибен төгәлләштерү максатларында тәкъдим ителә. 3 статьяга күрсәтелгән өлкәдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен төгәлләштерә торган үзгәреш кертелә.

**«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

Карала торган Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү «Татарстан Республикасы дәүләт милке һәм (яисә) муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасының дәүләт оешмасы, муниципаль оешма белән аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү хакында» 2022 елның 9 августындагы 775 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итми.